РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
САТЫШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Сатышево, улСоветская, 24
тел. (84362) 48-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САТЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатыш авылы, Совет урам,24 йорт
тел. (84362) 48-3-31

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
29.06.2020

КАРАР
№22

Сатыш авыл башкарма комитетының 19.05.2016 елның 33 нче номерлы “Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

Район прокуратурасының 19.06.2020 елның 02-08-02-77-2020 номерлы протесты һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 02.12.2009 ел, №390-ФЗ Федераль законы нигезендә Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Сатыш авыл башкарма комитетының 19.05.2016 елның 33 нче номерлы «Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1. Пункт 3.1. киләсе эчтәлектәге 3.1.1 пункты белән тулыландырырга:

“ 3.1.1. Планлы тикшерүнең еллык планына, планлы тикшерүләрне кертү өчен нигез булып, кабул иткән көннән бер ел үткәннән соң кертелә:

- дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;

- социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның муниципаль реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган Социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую (статья исеме 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә);

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;
- коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Шафигуллин